Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___20.01.2021______ Менделеевск ш. № ____21______

Менделеевск шәһәре территориясендә
кышкы чорда карны вакытлыча
өю урынын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Менделеевск шәһәре урамнарын вакытында һәм сыйфатлы кардан чистарту, шәһәр территорияләрен тиешле тәртиптә тоту, транспорт һәм җәяүлеләрнең куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итү, уңай экологик хәл булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Карны вакытлыча өю урыны итеп киләсе территорияләрне билгеләргә:
   - Менделеевск ш., Чоловский ур. буенча, шартлы рәвештә 16:27:110158:2311 кадастр номерлы, мәйданы 2000 кв.м булган җир кишәрлеге.
   - Менделеевск ш., Яр буе урамы буйлап, бетонлы мәйдан, 16:27:110163:116 кадастр номерлы, мәйданы 8000 кв.м булган җир кишәрлеге.
2. Менделеевск шәһәре территориясендә гомуми файдаланудагы юлларны карап тоту буенча эшләрне башкаручы барлык милек формасындагы оешмаларга кышкы чорда күрсәтелгән урында вакытлыча карны өяргә.
3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.А.Абдуллин